**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **23.11.2023 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Югары Стәрле авыл җирлегенә
керүче Түбән Стәрле авылында 2024 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә, Беек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләр, кендезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

 - Түбән Стәрле авылында юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү) ;
 -- Түбән Стәрле авылында күмелгән урыннарны карап тоту (тоташ гербицид белән химик эшкәртү, чүп-чар җыю, агач кисү, коймалау очен тозелеш материаллары сатып алу);
3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Югары Стәрле авылы, Совет., 32г йорт һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Тубән Стәрле авылы, Кызыл тан ур., 19 йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы Сабиржанова Л.С.